| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**10.09.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3084** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 03 ноябрендәге 3368 номерлы карары белән расланган, 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 7 декабрендәге 3907 номерлы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясындагы $3^2$ пунктының дүртенче абзацы, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының«Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2024 елга Россия Федерациясе бюджет классификациясенең кодларын (кодлар исемлеген) (2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына) раслау турында» Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2023 елның 01 июнендәге 80н номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 185н номерлы боерыгы нигезендә , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 03 ноябрендәге 3368 номерлы карары белән (2023 елның 7 декабрендәге 3907 номерлы үзгәрешләр белән) расланган, 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында , (алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Бюджет классификациясенең түбәндәге кодлары исемлеген тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| «805 | 2 02 45050 05 0000 150 | Дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, Россия Федерациясе субъектлары, Байконур шәһәре һәм "Сириус" федераль территориясе һөнәри белем бирү оешмаларының, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының һәм һөнәри белем бирү оешмаларының директорның балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек һәм тәрбия буенча киңәшчеләренә айлык акчалата бүләкләү түләүләрен тәэмин итүгә муниципаль районнар бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» |

1.2. Бюджет классификациясенең түбәндәге кодларын төшереп калдырырга:

| | | |
|---|---|---|
| «805 | 2 03 05000 05 0000 150 | Дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан муниципаль районнар бюджетларына керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр» |
| «805 | 2 04 05000 05 0000 150 | Дәүләтнеке булмаган оешмалардан муниципаль районнар бюджетларына керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр» |
| «805 | 2 07 05000 05 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетларына кире кайтарылмый торган башка кертемнәр» |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. ЗМР Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин